ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 19 мае**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1324**

2016-2020 елларга «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы турында

«Россия гражданнарына - арзанлы һәм уңайлы торак» өстенлекле милли проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 августындагы 889 номерлы «2015 - 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары, 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 09 декабрендәге 931 номерлы карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» гамәлгә ашыру максатларында, Зеленолольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2016 - 2020 елларга «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын (алга таба - программа) (1 нче кушымта) расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының
2016 елның 19 маендагы 1324 номерлы карарына
кушымта

**2016-2020 елларга «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»**
## МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ
Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2016-2020 елларга «Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | «Россия гражданнарына - арзанлы һәм уңайлы торак» өстенлекле милли проекты;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасы турында» карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 16 июлендәге 503 номерлы «2014 - 2015 елларда Татарстан Республикасында «Россия гражданнарына - арзанлы һәм уңайлы торак» өстенлекле милли проектын гамәлгә ашыру турында»гы карары;<br>1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 09 декабрендәге 931 номерлы «2014-2020 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» озак вакытлы максатчан программасы турында» карары. |
| Программаның төп эшләүчесе | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе |
| Программаның координаторлары | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары | Программаның төп максаты - торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү. |
| Программаның бурычлары | Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:<br>эконом классы торак сатып алу яки эконом классы индивидуаль торак йорт төзү өчен программада катнашучы яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү;<br>яшь гаиләләрнең үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән ипотека торак кредитлары һәм торак сатып алу яисә индивидуаль торак төзү өчен займнар бирүче өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру |
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2016 - 2020 еллар. |
| Программаны башкаручылар | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты; Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты каршындагы муниципаль торак фонды һәм торак сәясәте бүлеге, Башкарма комитетлар һәм авыл җирлекләре башлыклары; эконом классы торак урыннар бирү буенча вәкаләтле оешмалар; федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә сайлап алынган банклар |

## I. Программаның максатлары, бурычлары, принциплары һәм аны гамәлгә ашыру вакытлары

Программаның төп максаты - торак шартларны яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү юлы белән торак проблеманы хәл итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү.

Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

Программада катнашучы яшь гаиләләргә эконом класслы торак сатып алуга яисә эконом класслы индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләүләр бирүне тәэмин итү (алга таба - социаль түләүләр);

яшь гаиләләрнең үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән ипотека торак кредитлары һәм торак сатып алу яисә индивидуаль торак төзү өчен бурычка бирүче өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру. Яшь гаиләләр - Программада катнашучылар эконом класслы торак бина сатып алу өчен вәкаләтле оешмаларга мөрәҗәгать итә ала.

Программаны гамәлгә ашыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

Программада яшь гаиләләрнең катнашуының ирекле булуы;

яшь гаиләне закон нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

яшь гаиләләр өчен Программа кысаларында федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан торак шартларын яхшыртуга бер генә тапкыр бирелә торган акчалар исәбеннән ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге.

Программада яисә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүне күздә тоткан башка программада ( ярдәмче программада) катнашу хокукы яшь гаиләгә бирелә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты - 2016-2020 еллар.

## II. Программа чаралары системасы

Программа чаралары системасы федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

Федераль һәм региональ дәрәҗәдә оештыру чаралары 2015-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасы (алга таба - ярдәмче программа) составына керүче «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы чараларын һәм 2014-2020 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» озак вакытлы максатчан программасын (алга таба - республика программасы) гамәлгә ашыруны күздә тота.

Программаны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү буенча төп чаралар яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүнең финанс һәм икътисади механизмнарын эшләү һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләгәндә кирәкле техник-икътисади нигезләүләрне һәм хисапларны әзерләү булып тора.

Муниципаль дәрәҗәдә оештыру чаралары Зеленодольск муниципаль районында түбәндәгеләрне күздә тота:

яшь гаиләләрне законда билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен норматив-хокукый актлар кабул итү;

Программада катнашучы яшь гаиләләрне исәпкә алуны оештыруны;

социаль түләүләр алуга яшь гаиләләрнең исемлекләрен төзү;

яшь гаиләләргә билгеләнгән тәртиптә торак сатып алуга таныклыклар бирү.

Шулай ук муниципаль дәрәҗәдә оештыру чаралары үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне күздә тота:

Программада катнашучылар турында мәгълүматларның мәгълүмат-аналитик базасын булдыру;

Программа чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын бүлеп бирүгә заявкалар төзү;

Программаны гамәлгә ашыруның барышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

Программаны массакүләм мәгълүмат чараларында гамәлгә ашыру максатларын, бурычларын һәм нәтиҗәләрен яктыртуны тәэмин итү;

Программаны гамәлгә ашыру мониторингын үткәрү, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына - республика программасының дәүләт заказчысы тапшыру өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материаллары әзерләү.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның төп чыганаклары түбәндәгеләр:

федераль бюджет акчалары;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

банклар һәм башка оешмалар акчалары, шул исәптән яшь гаиләләргә ипотека торак кредитлары һәм торак сатып алуга яисә шәхси торак төзүгә займнар бирү;

сатып алына торган торак яисә төзелә торган шәхси торак хакын өлешчә түләү өчен кулланыла торган яшь гаиләләр акчалары.

Программаны еллык финанслауның фаразлау күләмнәрен федераль бюджет исәбеннән исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$Ф = \frac{Р+М}{1-У}\ х,У$$

биредә:

Ф - Программаның чараларын финанслашу өчен ел саен җәлеп ителә торган федераль бюджет акчаларының иң чик күләме;

Р - Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән еллык финанслау күләме;

М - муниципаль берәмлекләр бюджет акчалары исәбеннән Программаны еллык финанслау күләме;

У - субсидияләр исәбеннән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслау дәрәҗәсе.

Субсидияләр исәбеннән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслау дәрәҗәсенең әһәмияте түбәндәге формула буенча билгеләнә:

У=0,3/РБО,

биредә:

РБО - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 22 ноябрендәге 670 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне бүлү методикасы нигезендә исәпләнгән чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының исәп-хисап бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе.

Программаны федераль бюджет акчалары исәбеннән финанслауның факттагы күләме планлаштырыла торган елларда Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы үткәрә торган конкурс нигезендә сайлап алулар нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру механизмы яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүне күздә тота.

Яшь гаиләгә торак бина сатып алу (төзү) өчен социаль түләү Программага 1 нче кушымтада китерелгән кагыйдәләр нигезендә бирелә һәм кулланыла.

Бер бала туганда (уллыкка алынганда) яшь гаиләгә торак бина сатып алуга (төзүгә) өстәмә социаль түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 09 декабрендәге 931 номерлы «2014-2020 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» озак вакытлы максатчан программасы турында» карары белән расланган кагыйдәләр нигезендә бирелә һәм файдаланыла.

Социаль түләү бирү шарты - яшь гаиләнең торак бина төзү яисә сатып алу өчен кирәкле торак (төзү) сатып алуга кредит (займ) алу өчен, бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлешендә үз акчалары яисә җитәрлек керемнәре булу. Өстәмә акчалар сыйфатында яшь гаилә тарафыннан шулай ук ана (гаилә) капиталы акчалары (акчаларының бер өлеше) файдаланылырга мөмкин.

Яшь гаиләнең балигъ булган әгъзаларының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары тарафыннан яшь гаилә әгъзалары турында шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы ярдәмче программада катнашу һәм социаль түләү бирү шарты булып тора.

Килешү "Шәхси мәгълүматлар турында" Федераль законның 9 статьясы нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

Социаль түләүләрне яшь гаиләгә җиткерү механизмы сыйфатында, яшь гаиләнең Программаны гамәлгә ашыруда катнашуы турында карар кабул иткән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелә торган торак бина сатып алуга яисә индивидуаль торак йорт төзүгә социаль түләү алу хокукы турында таныклык (алга таба - таныклык) файдаланылачак. Алынган таныклык аның хуҗасы тарафыннан социаль түләүләр бирүгә каралган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен республика программасының дәүләт заказчысы тарафыннан сайлап алынган банкка тапшырыла, анда яшь гаилә әгъзасы исеменә социаль түләүне алу өчен билгеләнгән банк счеты ачыла. Яшь

гаилә - таныклык хуҗасы - торак сатып алу урыны буенча банк белән банк счеты килешүе төзи.

Яшь гаилә - таныклык хуҗасы банк счеты ачылган Программада катнашу өчен республика программасының дәүләт заказчысы тарафыннан сайлап алынган банкта ипотека торак кредиты алырга мөмкин. Торак сатып алу яисә шәхси торак төзү өчен займнар бирүче оешмалар программасында катнашу үзенчәлекләре дәүләт заказчысы билгеләгән республика программасы тәртибенә ярашлы рәвештә билгеләнә.

Программада катнашуга дәгъва кылучы банклар түбәндәге шартларны канәгатьләндерергә тиеш:

халыкны торак кредитлау тәҗрибәсе булу (халыкны торак кредитлау белән гамәлгә ашыру вакыты - 1 елдан артык);

барлык дәрәҗәдәге бюджетлар алдында салым түләүләрен түләү буенча бурыч булмау;

Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән мәҗбүри нормативларны үтәү;

соңгы хисап елында югалтулар булмау;

Татарстан Республикасы территориясендә банкның структур бүлекчәсе булу;

Татарстан Республикасы территориясендә филиаллар челтәре үсеше;

ипотека торак кредитлары бирү шартлары.

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» - Программаның координаторы түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Программада катнашучыларның эшен координацияләү;

Программаны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат-аңлату эшләре алып бару;

республика программасының дәүләт заказчысы, вәкаләтле оешмалар, банк белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Программаны тормышка ашыру буенча йөкләнгән бурычларны исәпкә алып, Программа чараларын тулысынча һәм үз вакытында башкаруны тәэмин итү.

республика программасында катнашуга Зеленодольск муниципаль районы заявкасын яклау;

программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинглау;

дәүләт заказчысына республика программасын тапшыру өчен мәгълүмати-аналитик һәм хисап материаллары әзерләү.

## V. Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа чараларын уңышлы үтәү 2016 - 2020 елларда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итәргә, шулай ук түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

торак өлкәсенә ипотека торак кредитлары һәм займнар, гражданнарның үз акчалары бирә торган банкларның һәм башка оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү;

җәмгыятьтә уңай демографик тенденцияләрне үстерү һәм ныгыту;

гаилә мөнәсәбәтләрен ныгыту һәм җәмгыятьтә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметү;

ипотека торак кредитлау системасын үстерү;

торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме рәвешләрен киңәйтү һәм яшь гаиләләр өчен торак алу мөмкинлеген арттыру.

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү һәм аңа бүлеп бирелгән федераль һәм республика бюджетларының акчаларын файдалану республика программасында каралган критерийларны һәм индикаторларны исәпкә алып гамәлгә ашырылачак.

Торак шартларын тудырган яшь гаиләләрнең ахыргы саны Программаны финанслау күләмнәреннән, яшь гаиләләр составының саныннан һәм яшь гаиләләргә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен кулланыла торган муниципаль берәмлек буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткеченә турыдан-туры бәйле. Муниципаль берәмлек буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткече Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган Татарстан Республикасы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткеченнән югарырак була алмый.

Башкарма комитетның 2016 елның
19 маендагы 1324 номерлы карары
белән расланган 2016-2020 елларга
«Зеленодольск муниципаль
районында яшь гаиләләрне торак
белән тәэмин итү» максатчан
программасына
1 номерлы кушымта

**«Зеленодольск муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләре**
**2016-2020 елларга**

1. Әлеге Кагыйдәләр яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә шәхси торак йорт төзүгә вәкаләтле оешмалар һәм сайлап алынган банклар аша торак сатып алуга яисә торак ипотека кредиты яисә займ алганда яисә шәхси торак йорт төзүгә, республика программасының дәүләт заказчысы билгеләгән тәртип (норматив документ) нигезендә башлангыч кертем түләүгә, шулай ук әлеге ипотека торак кредитлары яисә займнары буенча процентлар һәм бурычның төп суммасын түләүгә (алга таба - социаль түләүләр) гамәлгә ашыруда юнәлтелергә мөмкин катнашу өчен, шул исәптән 2011 елның 1 гыйнварына кадәр алынган социаль түләүләр бирү тәртибен билгели.

Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 номерлы карары белән расланган 2014-2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының "Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" (алга таба - ярдәмче программасы) ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләүләр бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

2. Социаль түләү алуга Программада катнашучы яшь гаиләнең хокукы исемдәге документ - таныклык (алга таба - таныклык) белән таныклана, ул кыймммәтле кәгазь була алмый.

3. Федераль ярдәмче программада билгеләнгән форма буенча таныклык бирү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла, карар нигезендә яшь гаилә Программада катнашучылар исемлегенә кертелгән.

4. Таныклыкның гамәлдә булу вакыты таныклыкта күрсәтелгән бирелү датасыннан кимендә 9 ай тәшкил итә.

5. Программаны гамәлгә ашыру кысаларында социаль түләү алуга дәгъва кылучы яшь гаилә, шул исәптән бер һәм аннан да күбрәк баласы булган, ир белән хатынның берсе Россия Федерациясе гражданы булмаган яшь гаилә, шулай ук Россия Федерациясе гражданы булып торучы яшь ата-ананың берсе һәм түбәндәге шартларга туры килә торган бер һәм аннан да күбрәк баласы булган тулы булмаган яшь гаилә булырга мөмкин:

а) яшь гаиләне - Программада катнашучыны планлаштырылган елда (1 гыйнварга) ир белән хатынның һәркайсының яисә тулы булмаган гаиләдәге

ата-ананың берсенең яшен социаль түләү алуга дәгъва кылучылар исемлегенә кертү турындагы карары республика программасы  дәүләт заказчысы тарафыннан кабул ителгәндә 35 яшьтән артмаганда, ягъни планлаштырыла торган елның 1 гыйнварына 36 яшь тулырга тиеш түгел;

б) яшь гаилә әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылса;

в) Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яшәү урыны буенча балаларны да кертеп, яшь гаиләнең барлык әгъзаларын теркәү;

г) гаиләнең әлеге Кагыйдәләрнең 7 пункты нигезендә бирелә торган социаль түләү күләменнән артып китүче өлешендә торакның исәп-хисап (уртача) бәясенә түләү өчен җитәрлек чаралары, керемнәре яисә башка акчалары булу.

6. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар дип 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куелган яшь гаиләләр, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан аларның даими яшәү урыны буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләр 2005 елның 1 мартыннан соң, гражданнарны социаль найм килешүләре буенча бирелә торган торак биналарга мохтаҗлар дип тану өчен Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясында билгеләнгән нигезләрдә, торак биналарга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куелуга карамастан яшь гаиләләр аңлашыла.

7. Яшь гаиләнең бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлештә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен җитәрлек күләмдә керемнәре яисә башка акчалары булу дигәндә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән яшәү минимумының җыелма керем дәрәҗәсе ким булырга тиеш түгел дип аңлашыла.

8. Программада катнашу ирекле.

Ярдәмче программа кысаларында социаль түләүдән файдаланып торак шартларын яхшыртуга хокук яшь гаиләгә бер генә тапкыр бирелә.

9. Социаль түләү түбәндәге күләмдә бирелә:

әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең 30 проценты - балалары булмаган яшь гаиләләр өчен;

әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең 35 проценты - 1 балалы һәм аннан да күбрәк баласы булган яшь гаиләләр өчен, шулай ук 1 яшь ата-ана һәм 1 һәм аннан да күбрәк баласы булган  тулы булмаган яшь гаиләләр өчен.

Соңгысын түләүгә социаль түләү кулланылган очракта, пай кертемен түләү исәбенә аның күләме, әлеге Кагыйдәләрнең 9 пункты нигезендә билгеләнә һәм  пай калдыгын түләү буенча бурыч калган сумма белән чикләнә.

10. Социаль түләү күләме төрле сандагы гаиләләр өчен билгеләнгән торак бинаның гомуми мәйданы күләменнән, Программада катнашучы яшь гаилә әгъзалары санынннан һәм Зеленодольск муниципаль районындагы гомуми торак мәйданының 1 кв. метры норма бәясеннән чыгып исәпләнә. Социаль түләү күләмен исәпләү өчен Зеленодольск муниципаль районындагы гомуми торак мәйданының 1 кв. метры бәясенең нормативы җирле үзидарә органы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв.

метрының уртача базар бәясеннән югарырак билгеләнми, ул вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

10.1 Ир белән хатынның берсе Россия Федерациясе гражданы булмаган яшь гаилә өчен социаль түләү күләмен исәпләү әлеге Кагыйдәләрнең 10 пункты нигезендә Россия Федерациясе гражданнары булган гаилә әгъзаларын исәпкә алып, күпсанлы гаиләләр өчен билгеләнгән торак бинаның гомуми мәйданы күләменнән чыгып башкарыла.

11. Социаль түләү күләме исәпкә алына торган торак бинаның гомуми мәйданы күләме:

2 кеше яшәгән гаилә өчен (яшь ир яисә хатын яисә 1 яшь ата яисә ана яисә бала) - 42 кв. метр;

3 һәм аннан да күбрәк кеше булган гаилә өчен үз эченә яшь парлардан тыш 1 һәм аннан да күбрәк бала (яки 1 яшь ата (ана) һәм 2 һәм аннан да күбрәк бала булган гаилә) 1 кешегә 18 кв. метр.

12. Социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

СтЖ = Н х РЖ

биредә:

СтЖ - социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган торакның исәп-хисап (уртача) бәясе;

Н - әлеге Кагыйдәләрнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә торган торакның гомуми мәйданының 1 кв. метры бәя нормативы;

РЖ - әлеге Кагыйдәләрнең 11 пункты нигезендә билгеләнә торган торак урынның гомуми мәйданы күләме.

13. Социаль түләү күләме таныклык бирү датасына исәп тота, таныклыкта күрсәтелә һәм аның гамәлдә булу вакыты дәвамында үзгәрешсез кала.

14. Программада катнашу өчен яшь гаилә барлык гаилә әгъзаларына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенә түбәндәге документларның күчермәләрен һәм төп нөсхәләрен тапшыра:

а) җирле үзидарә органы тарафыннан торак законнарында каралган нигезләрдә яшь гаиләне 2014 - 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын һәм 2014-2020 елларга «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» озак вакытлы максатчан программасын гамәлгә ашыруда катнашу мөмкинлеге өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында гариза, форма буенча әлеге Кагыйдәләрнең 1 нче кушымтасы нигезендә ике нөсхәдә (бер нөсхә мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны теркәү датасын күрсәтеп кайтарыла);

б) әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны әлеге Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасында күрсәтелгән исемлек нигезендә яисә ипотека торак кредиты (займ) акчаларыннан файдаланып сатып алынган (төзелгән) торак бинага милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык һәм яшь гаиләне тиешле кредит килешүе (займ килешүе) төзелгән вакытта торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны

раслый торган документлар, ләкин 2006 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел. Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тануны раслый торган документ - Башкарма комитет комиссиясе һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан тиешле карар;

в) гаиләнең Программага 2 нче кушымтада күрсәтелгән исемлек нигезендә бирелә торган социаль түләү күләменнән артып киткән өлешендә торакның исәп (уртача) бәясенә түләү өчен җитәрлек керемнәре яисә башка акчалар булуын раслый торган документлар;

Яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану турында документы булганда "а" пунктчасында күрсәтелгән гариза бирелми.

г) планлаштырыла торган елда әлеге Кагыйдәләргә 4 нче кушымта нигезендә форма бунча ике нөсхәдә, торак шартларын һәм түләү сәләтен яхшыртуга мохтаҗлыкны раслау өчен кирәкле документларны теркәп, социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрне исемлеккә кертүгә гариза (гаризаның бер нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны кабул итү датасын күрсәтеп, кайта);

д) «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә яшь гаилә әгъзалары турында персональ мәгълүматларне җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары тарафыннан эшкәртүгә яшь гаиләнең балигъ булган әгъзаларының язма ризалыгы;

е) Яшь гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану һәм яшь гаиләнең бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлештә торакның исәп (уртача) бәясенә түләү өчен җитәрлек булган башка акчаларының булуын раслау өчен кирәкле документлар исемлеге әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтада китерелгән.

15. Югарыда күрсәтелгән гариза гражданнарның гаризаларын теркәү журналында теркәлә, анда теркәлү номеры, яшь гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме, документлар тапшыру датасы һәм вакыты, документлар комплектын тапшырган затның имзасы, документлар комплектын кабул иткән вазыйфаи затның имзасы күрсәтелә.

16. Әлеге Кагыйдәләрнең 14, 25 пунктларында каралган документларны яшь гаилә исеменнән аның бер әгъзасы яисә тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан бирелергә мөмкин.

17. Башкарма комитет комиссиясе һәм авыл җирлеге Башлыгы яшь гаилә тәкъдим иткән документлардагы белешмәләрне тикшерә һәм документларның тулы пакетын тапшыру датасыннан 10 көн эчендә яшь гаиләне тану турында яисә танымау турында карарлар кабул итә:

- әлеге Кагыйдәләргә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ;

- бирелә торган социаль түләү күләменнән зуррак өлештә торакның исәп-хисап (уртача) бәясенә түләү өчен җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары бар.

- Программада катнашучылар һәм планлаштырыла торган елда социаль түләүне алу теләген белдергән яшь гаиләләр исемлегенә кертү турында (алга таба - исемлек).

18. Кабул ителгән карар 5 эш көне эчендә кабул ителгән карарның нигезлелеген, шулай ук җирле үзидарә Башкарма комитетының тиешле күрсәтмәсенең реквизитларын яшь гаилә әгъзаларына шәхсән яисә заказлы почта хәбәрнамәсе белән күрсәтеп, тиешле хәбәрнамә тапшыру юлы белән яшь гаиләгә җиткерелә.

19. ТР ЗМР яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе" Программасының дәүләт заказчысы соравы буенча:

а) 30 көн эчендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә, планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрнең исемлекләрен төзү турындагы мәгълүматны җиткерә һәм яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән тиешле документларны күрсәтеп, бирелә торган социаль түләү күләменнән арткан өлештә торакның хисап (урта) хакын түләү өчен җитәрлек булган башка акчаларны раслау зарурлыгы турында 30 көн эчендә хәбәр итә;

б) әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрне тикшерә һәм әлеге документларны тапшыру датасыннан 10 көн эчендә планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенә кертү турында яисә кертүдән баш тарту турында әлеге Кагыйдәләрнең 17 пунктында каралган нигезләрдә карар кабул итә;

в) Программаның дәүләт заказчысы күрсәтелгән вакытларда, Программаны гамәлгә ашыру кысаларында планлаштырыла торган елда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык, социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрнең исемлекләрен төзи һәм тапшыра, аларның керемнәре яисә хисаплы (уртача) торак бәясе өлешендә түләү өчен җитәрлек булган башка акчалары булган, бирелә торган социаль түләү күләменнән (кабат теркәлү узган) артыграк булган һәм социаль түләүне планлаштырылган елда алырга теләк белдергән (алга таба - тиешле елда социаль түләүне алу теләген белдергән) язма рәвештә әлеге Кагыйдәләргә 4 нче кушымта нигезендә.

Планлаштырылган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенең формасы Программаның дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнә.

20. Планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлеге яшь гаиләне Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану датасын исәпкә алып төзелә. Әлеге исемлекләргә беренче чиратта 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куелган яшь гаиләләр, шулай ук 3 һәм аннан күбрәк баласы булган яшь гаиләләр керә.

21.Программада катнашучылар дип танудан баш тарту һәм яшь гаиләне исемлеккә кертмәү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) яшь гаиләнең әлеге Кагыйдәләрнең пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

б) әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау;

в) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

г) ярдәмче программа кысаларында социаль түләүдән файдаланып, яшь гаилә тарафыннан элек гамәлгә ашырылган торак шартларын яхшыртуга хокук;

д) шәхси гариза.

22. Программада катнашу турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итү әлеге Кагыйдәләрнең 21 пунктында каралган баш тарту өчен нигезләр бетерелгәннән соң рөхсәт ителә.

23. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе республика программасының дәүләт заказчысы рәсми мөрәҗәгате буенча күрсәтелгән вакытларда Исемлекне тапшыра, аның формасы республика программасының дәүләт заказчысы тарафыннан билгеләнә.

